# 1-4 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбият» фәнен федераль белем бирү программаларына нигезләнеп укыту буенча методик тәкъдимнәр

Әдәби уку. 1 сыйныф: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 127 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/1snf/

Әдәби уку. 2 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 96 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part1/

Әдәби уку. 2 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 144 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/2snf/part2/

Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 100 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 112 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

Әдәби уку. 4 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 76 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part1/

Әдәби уку. 4 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты. – 116 б.http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/4snf/part2/

## Аңлатма язуы

Башлангыч белем бирү системасында «Туган телдәге (татар телендә) әдәби уку» предметының үз урыны бар. Бу аның «Әлифба» китабыннан соң укучыны яңа этапка алып чыгуы белән генә бәйле түгел. Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләбеннән чыгып караганда, «Туган телдәге (татар телендә) әдәби уку» предметының максатлары һәм бурычлары элеккеге «Уку» предметыныкыннан шактый аерыла. Ул уку тизлеген арттыру, аңлап уку, укыганның эчтәлеген сөйләү, план төзү, әсәрне өлешләргә бүлү, эчтәлеккә кагылышлы сорауларга җавап бирү кебек төп эшләр белән беррәттән, әсәрне сәнгатьнең бер төре буларак кабул итәргә өйрәтә. Бу – баланың укыганны хисләр дәрәҗәсендә кабул итүенә ирешү. Шуның белән ул аның рухын тәрбияли, шәхес буларак камилләштерә, фикерләргә, чагыштыру-анализлау ярдәмендә нәтиҗәләр ясарга, тормышчан ситуацияләрдә аларны куллана белергә өйрәтә.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку»курсы укучыларның милли мәдәният белән кызыксынуын формалаштыра, милли мохиткә алып керә, татар әдәбияты һәм сәнгатеннән кирәкле мәгълүмат эзләү, табу мөмкинлекләренә өйрәтә.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку»предметыннан Федераль эш программаларына жанр һәм тематик яктан бай, эстетик һәм әхлакый кыйммәте югары, укучыны кызыксындыра алырлык татар балалар әдәбияты һәм татар фольклорының иң яхшы үрнәкләре сайлап алынды. Әдәби материал татар халкының этномәдәни мирасын чагылдырырлык тематик бүлекләр кысаларында укучыларның яшь үзенчәлекләренә тәңгәл китереп тәкъдим ителә.Программада әхлакый камиллек, аңлы җаваплылык, патриотик хисләр, туган якка, Туган илгә мәхәббәт тәрбияләүгә, укучының үз милли тәңгәллеген аңлы кабул итүенә ныклы игътибар бирелә.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку»предметының төп максаты татар мәдәниятенең мөһим өлеше булган туган (татар) телдәге әдәбиятка сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, укучыларның мәдәни мираска, үз халкының гореф-гадәтләренә тартылуын тәэмин итү, киләчәктә куелган уку бурычыннан чыгып, шулай ук үзләре кызыксынган өлкәгә караган китапларны китапханәләрдән мөстәкыйль рәвештә сайлап ала алырлык грамоталы укучы формалаштыру.

Максатларны тормышка ашыру түбәндәге бурычларны хәл итә:

– укуга һәм китапка карата кызыксыну тәрбияләү, укучының тормышны күзаллавын формалаштыру;

– укучыларның аралашу (коммуникатив) сәләтен булдыру;

– укучыларның туган (татар) телендә телдән һәм язма диалогик, монологик сөйләмен үстерү;

– кычкырып һәм эчтән (үз-үзеңә) уку техникасын булдыру һәм камилләштерү, текстны төшенү (кабул итү һәм аңлау) алымнарын үстерү, эшчәнлекнең универсаль төрләренә – күзәтүгә, чагыштырма анализга өйрәтү;

– әдәби анализ элементларын куллану аша укучыларны сүз сәнгатенә, туган телдәге әдәбиятка якынайту, аерым әдәби-теоретик төшенчәләр белән таныштыру;

– укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру, әсәрләрнең рухи асылын аңларга өйрәтү;

– туган (татар) телендә иҗади эшчәнлек сәләтләрен үстерү.

Алда күрсәтелгән дәреслекләрнең һәр темасы өйрәнелә торган әсәр белән бәйләп бирелә. Теманы өйрәнүнең башыннан ахырына кадәр укучылар белән белемнәрне дәреслек персонаж-геройлары үзләштерә. Әлеге әдәби геройлар укучылар белән өйрәнелә торган темага һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле сөйләшү алып баралар. Персонажлар белән әңгәмә теманың башында һәм ахырында бирелә. Әлеге әңгәмәләр һәм төрле коммуникатив юнәлешле биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерүгә хезмәт итәләр. Мондый диалоглар укучыларның күңелләрен күтәрә, дәрес башында куелган уку мәсьәләсен төшенергә булыша, теге яки бу әдәби әсәрне өйрәнүгә мотивлаштыра.

Дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус), ягъни ике дәрәҗәдә укуны (предметның база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне), димәк, бер-берсеннән бик нык аерылып торган укучыларга белем бирүне күздә тота. Дәреслектә төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материаллар аерып бирелә. Предметны тирәтен өйрәнүчеләр өчен генә булган өлешләр дәреслек битләрендә төс һәм график сурәт (яшел пунктирлар) ярдәмендә билгеләнә. Сорау-биремнәр дә ике дәрәҗәгә аерып бирелә.

Дәреслектәге биремнәр, аеруча база өлешендәгеләре, укучыга авырлык тудырырлык түгел. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган өстәмә материаллар, сорау-биремнәр укучыларның иҗади мөмкинлекләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлауларын күздә тота.

Әдәби текстtан соң укучыларга сүзлекчә тәкъдим ителә. Биредә текстта очраган таныш булмаган сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә. Бу – телне төрле дәрәҗәдә белгән укучыларга әдәби текстны кабул итү һәм аңлауны берникадәр җиңеләйтәчәк.Дәреслектә үзләштерү өчен, әдәби-теоретик төшенчәләр дә тәкъдим ителә. Аларның саны күп түгел.

Ятлау өчен бер уку елына 3 – 4 әсәр бирелә. Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә аларның саны чагыштырмача күбрәк.

Үткән материалны кабатлау төрле формада оештырыла. Ул традицион сорау-биремнәргә җавап бирү рәвешен дә, укылган әсәрләр буенча квест-уен, кроссвордлар чишү, дидактик характердагы төрле әдәби уеннар рәвешен дә ала.Табышмаклар, ребуслар аерым теманы өйрәнгән вакытта да тәкъдим ителә. Бу – укучыларга эмоциональ яктан тәэсир ясый, дәрескә куелган уку мәсьәләсен аңларга ярдәм итә, яңа әдәби материалны өйрәнүне мотивлаштыра.

Китапханәләрнең әдәбият белән тиешле күләмдә тәэмин ителмәвен, аерым әсәрләрне Интернет чыганакларда табып булмавын исәпкә алып, дәрестән тыш уку өчен билгеләнгән әсәрләр дә дәреслектә кертелде.

«Әдәби уку» дәреслеге белән «Туган тел (татар теле)» дәреслеге бер-берсен тулыландырып бара. Бу эш темаларда да, компетенциядә дә чагылыш таба. Балалар ияләшеп өлгергән персонажлар ике дәреслектә дә очрый.

Төп материал белән беррәттән дәреслекнең электрон вариантында һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Алар балаларның кызыксыну даирәләрен, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнде. Шулай ук биредә аерым текстларның аудиоязмалары урын алган. Текст белән эшләгәндә аларны тыңлатып була.

**ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ**

**1 класс- 33 сәг**

| № | Дәреснең темасы | Сәг саны | Үткәрү вакыты | | Ис-кәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | План | Факт | |
| 1 | “Өч кыз”,”Куян кызы” әкиятләре. Предметны, предметның билгесен белдерүче сүзләр. Әкият текстын тыңлау. Иллюстрацияләрнең (рәсемнәрнең) текст өлешләре белән бәйләнешен (мөнәсәбәтен) ачыклау. Әкият эчтәлеген сөйләү. Балаларда текст турында, беренчедән, мәгънә ягыннан үзара бәйләнгән һәм хәбәр итү интонациясе белән әйтелә торган, якынча тәмамланган фикерне белдерүче, билгеле бер эзлеклелектә килгән сүз һәм җөмләләр җыелмасы буларак, икенчендән, нәрсә турында да булса хәбәр итүче һәм ишетеп, күреп зиһенгә алына торган мәгълүмат буларак башлангыч күзаллау булдыру. | 1 | 04.09 | | |
| 2 | Сүз һәм аның лексик мәгънәсе. [а], [ә] авазлары. А,а; Ә,ә хәрефләре. Иллюстрация темасы буенча җөмләләр төзү. | 1 | 11.09 | | |
| 3 | Сүздәге авазларның санын һәм эзлеклелеген билгеләү.<br>[ы] , [э], [и] авазлары. Э,э; И,и ; Ы,ы хәрефләре. | 1 | 18.09 | | |
| 4 | Аваз, иҗек, сүз, җөмлә һәм текст турында образлы күзаллау формалаштыру.<br>[ү] ; [у] авазы. Ү,ү ; У,у хәрефләре. | 1 | 25.09 | | |
| 5 | Калын һәм нечкә сузыкларны аеру, аларны хәрефләр белән белдерү. [о] ; [ө] авазы. О,о ; Ө,ө хәрефләре. | 1 | 02.10 | | |
| 6 | Сузык һәм тартык авазлар. Тартык авазларның яңгыраулыгын белдерүче билге — уртасында нокта булган квадрат белән билгеләү. [н] авазы. Н,н хәрефләре. Иҗек. Иҗек калыплары. Иҗекләп уку күнекмәләрен формалаштыру (сузык аваз хәрефләренә карап, сүзләрне калын һәм нечкә итеп уку). [л] авазы. Л, л хәрефләре. | 1 | 09.10 | | |
| 7 | Әйтелгән сүздән аерым сузык яки тартык авазны ишетеп, аерып алу. [м] авазы, М,м хәрефләре. Сүзләрне иҗекләргә бүлү, сүз басымын билгеләү. Басымлы һәм басымсыз сузыкларны аеру. [р] | 1 | 16.10 | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | авазы. Р,р хәрефләре кергән сүзләрне уку. Сүз кисәге буларак иҗек турында белешмә | | | | |
| 8 | Сүз һәм җөмләне аеру. Сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне һәм кыска текстларны аңлап уку. [й], [ң] авазлары, Й,й ; ң хәрефләре | 1 | 23.10 | | |
| 9 | Калын һәм нечкә әйтелешле сүзләрдә сузык авазларның роле. Я,я; Ю, ю; Е,е хәрефләре, аларның аваз мәгънәләре. Е-ё, ю, я хәрефләренең кулланылышы. | 1 | 13.11 | | |
| 10 | Сюжетлы рәсемнәр, үзеңнең уеннарың, күзәтүләрең буенча хикәяләү характерындагы зур булмаган текстлар төзү. Яңгырау һәм саңгырау тартык авазларны аеру. [д], [т] авазлары, Д,д; Т,т хәрефләре. | 1 | 20.11 | | |
| 11 | Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, иҗекләрне һәм сүзләрне тиешле тизлек белән уку. [з], [с] авазлары, З,з; С,с хәрефләре. | 1 | 27.11 | | |
| 12 | Бер яки берничә авазы белән аерыла торган сүзләрне чагыштыру. [г] ,[гъ] [к],[къ] авазлары, Г,г ; К,к хәрефләре. | 1 | 04.12 | | |
| 13 | Укыганда орфоэпия нормаларын төгәл саклау, дөрес тавыш төсмерләре белән укырга өйрәтү. [W],[в],[ф] авазлары. В,в; Ф,ф хәрефләре. | 1 | 11.12 | | |
| 14 | [б] [п] авазлары. Б,б ; П,п хәрефләре | 1 | 18.12 | | |
| 15 | Зур булмаган текстны һәм шигырьләрнең эчтәлеген аңлап, сәнгатьле итеп уку . [ж] , [ш] авазлары, Ж,ж ; Ш,ш хәрефләре | 1 | 25.12 | | |
| 16 | Тиз һәм йөгерек уку. [җ] , [ч] авазлары, Җ,җ ;Ч,ч хәрефләре. | 1 | 15.01 | | |
| 17 | [х], [h] авазлары. Х,х; Һ,һ хәрефләре. | 1 | 22.01 | | |
| 18 | Гади җөмлә ахырындагы тыныш билгеләренә игътибар итеп, тиңдәш кисәкләрне, эндәш сүзләрне тиешле интонация һәм пауза белән уку. Е,е хәрефләре. [щ] , . [ц] авазлары, Щ,щ ; Ц,ц хәрефләре. | 1 | 29.01 | | |
| 19 | Укылган текстның эчтәлеген аңлау. Нечкәлек(ь) , калынлык (ъ) билгеләренең кулланылышы | 1 | 05.02 | | |

**1 класс – 18 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | | | Укучылар эшчәнлегенең төрләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 20<br>21<br>22<br>23<br>24<br>25 | Өйрәтәләр мәктәпләрдә...<br>(8сәгать) | Әйдәгез, танышабыз! (Җ. Дәрзаман. «Тискәре хәрефләр») | 1 | 12.02 | | Әңгәмә: дәреслек, шартлы билгеләр белән танышу.<br>Текстны аңлап уку.<br>Әсәрнең гомуми эчтәлеген аңлау.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Күзәтү: иллюстрацияләр карау.<br>Әсәр героен характерлау: аның эш-гамәлләрен бәяләү.<br>Терәк сүзләр буенча әсәрнең эчтәлеген сөйләү.<br>Парлап эшләү: үрнәк буенча диалог төзү.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле яттан сөйләү.<br>Күнегү: дәфтәрдә язма күнегүләрне эшләү |
| | | Мәктәптә беренче көн (М.Мәһдиев. «Мәктәптә беренче көн»)<br>Өйрәтәләр мәктәпләрдә (М. Җәлил. «Беренче дәрес») | 1 | 26.02 | | |
| | | Иң татлы тел – туган тел (Ш. Маннур.«Яхшы бел») | 1 | 04.03 | | |
| | | Туган җир якын, туган тел якын (Х. Туфан. «Казан») | 1 | 11.03 | | |
| | | Рәсем дәресендә<br>(Б. Рәхмәт. «Рәсемнәр ясыйбыз»,<br>Н. Мадьяров. «Салават күпере») | 1 | 18.03 | | |
| | | Якты йөзле укытучым (В. Голявкин. «Парта астында») Мәктәп – белем йорты (кабатлау) | 1 | 01.04 | | |
| 26<br>27<br>28<br>29 | Минем гаилә<br>(5 сәгать) | Безнең гаиләбез<br>(Г. Тукай. «Безнең гаилә», Н. Мадьяров. «Булышабыз») | 1 | 08.04 | | Текстны аңлап уку.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар белән раслау.<br>Әдәби әсәрнең текстын характерлау:укылган текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, вакыйгаларны дөрес тәртиптә урнаштыру.<br>Әдәби геройны характерлау.<br>Парлап эшләү: үрнәккә карап диалог төзү.<br>Сөйләү: хикәяләү характерындагы хикәя төзү.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Күнегү: дәфтәрдә язма |
| | | Әниемнең әнисе әбием була миңа (Ш. Галиев. «Дәү әнигә күчтәнәч», А. Алиш. «Әбиләрдә кунакта») | 1 | 15.04 | | |
| | | Барысын да яратам (Р. Вәлиев. «Барысын да яратам», Г. Әдһәм. «Кызыл муенса») | 1 | 22.04 | | |
| | | Исемең матур кемнәр куйган (Җ. Дәрзаман. «Исем таптым») Өй әдәпләре (кабатлау) | 1 | 29.04 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | күнегүләрне эшләү. Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлау |
| 30 31 | Татар халык иҗаты Санамышлар, эндәшләр (2 сәгать) | Кояш чык, болыт кач! (эндәшләр) (Ф. Садриев. «Яңгыр, яу, яу, яу!») | 1 | 06.05 | | Тыңлау: сүзнең аваз һәм мәгънәви ягын, тыңлаган сөйләмне аңлау. Уку диалогы: сорауларга телдән җавап бирү. Сүзлек эше: сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итү. Фольклорның кече жанрларын аеру. Әдәби әсәр тексты өстендә эш: тексттагы образлылыкны аңлау. Иҗади эш: үрнәккә карап санамышлар, эндәшләр иҗат итү |
| | | Карга әйтә: «кар-карр!» (санамышлар) (Н. Арсланов. «Яз») | 1 | 13.05 | | |
| 32 33 | Табигать яме (3 сәгать) | Мин урамны күзәтәм (И.Туктар. «Җем-жем!.. Чвик...!», «Серле тартма») | 1 | 20.05 | | Текстны аңлап уку. Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. Сөйләү: үрнәккә карап тәкъдим ителгән темага телдән сөйләү. Текст белән эш: геройның хис-кичерешләрен сурәтләү чараларын билгеләү, әдәби чараларның текстта урынын табу һәм мәгънәсен аңлау. Күнегү: дәфтәрдә язма күнегүләрне эшләү. Проект эшләү: хәрефләр турында китапчык төзү. Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлау |
| | | Ямьле җәй җитә-ә-ә! (Ш. Галиев. «Тәмле җәй», Ф. Зариф. «Татлы җәй») Нәрсәләр белдек? | 1 | | | |

**2 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| | Тема | Эчтәлек | Сәг. сан ы | Үткәрү вакыты | | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт | |
| 1 | Алтын көз җитте (7 сәгать) | Әйдәгез мәктәпкә! (Б. Рәхмәт. «Сара мәктәпкә бара», Р. Миңнуллин. «Исәнме, мәктәбем!») | 1 | 05.09 | | Текстның эчтәлеген аңлау максатыннан кычкырып уку. Укылган текстның мәгънәсен аңлау. Укылган текст буенча әңгәмә. Сорауларга җаваплар бирү. Текст нигезендә сораулар төзү. Терәк сүзләрне кулланып текстның эчтәлеген сөйләү. Укылган текстка нигезләнеп монологик сөйләм булдыру. Әдәби текст белән эш: тел-сурәтләү чараларын табу Иҗади эш: укылган текст эчтәлеге буенча рәсем ясау. Тормыш тәҗрибәсе, шәхси күзәтүләргә нигезләнеп сөйләү. Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү. Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Килеп җиткән алтын көз (Р. Вәлиева. «Көз») | 1 | 12.09 | | |
| | | Көзге бакча (Г. Хәсәнов. «Көзге бакча») | 1 | 19.09 | | |
| | | Яфраклар ява җиргә (Л. Лерон. «Яфрак бәйрәме») | 1 | 26.09 | | |
| | | Көзге табын(Ф. Яруллин. «Көзге табын») | 1 | 03.10 | | |
| | | Урман букеты (И. Туктар. «Урман букеты», К. Тәхау. «Көзге урман») | 1 | 10.10 | | |
| | | Хушлашабыз көз белән (кабатлау) | 1 | 17.10 | | |
| 2 | Татар халык иҗаты (2 сәгать) | Халык әйтсә, хак әйтә | 1 | 24.10 | | Тыңлау: сөйләмне тыңлап кабул итү, сүзнең яңгырашын һәм мәгънәсен бердәй кабул итү. Сүзлек эше: аңлатмалы сүзлектән табып, сүзләрнең мәгънәсен аңлату. Әдәби текст белән эш: тел-сурәтләү чараларын табу, образлар системасын билгеләү. Татар халык авыз иҗатыда кече жанрларның аермасын белү. Иҗади эш: үрнәк буенча табышмак иҗат итү |
| | | Акылсызга әйтсәң – көлә, зирәккә әйтсәң – белә | 1 | 07.11 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 3 | И ямьле дә соң бу дөнья! (4 сәгать) | И ямьле дә соң дөнья! (Л. Лерон «И ямьле дә соң бу дөнья!») | 1 | 14.11 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку, кычкырып укудан эчтән укуга күчү. Укылганның эчтәлеген аңлау. Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү. Әдәби текст белән эш: әсәрнең төп фикерен билгеләү, бирелгән мәкальләр арасыннан әсәрнең төп фикеренә туры килә торганын сайлап алу. Төрле язучыларның бер темага язылган әсәрләрен чагыштыру, геройның хис-кичерешләрен сурәтләү чараларын билгеләү, әдәби чараларның текстта урынын табу һәм мәгънәсен аңлау. Текст буенча сораулар төзү. Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле яттан сөйләү. Иҗади эш: укылган текст эчтәлеге буенча рәсем ясау. Проект эше эшләү. Сыйныфтан тыш уку:тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |
| | | Балачак иле – зәңгәр ил (Р. Гаташ. «Зәңгәр ил – балачак иле») | 1 | 21.11 | | |
| | | Эш беткәч уйнарга ярый (Г. Тукай. «Эш беткәч уйнарга ярый») | 1 | 28.11 | | |
| | | Соклангыч дөнья (кабатлау) | 1 | 05.12 | | |
| 4 | Ап-ак кыш килде (5сәгать) | Кышкы кунак (А. Алиш. «Январь», Г. Афзал. «Беренче кар») | 1 | 12.12 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку, кычкырып укудан эчтән укуга күчү. Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү. Әдәби текст белән эш: укылган текстның темасын, сурәтләү чараларын билгеләү. Укылган текстка нигезләнеп, монологик сөйләм булдыру. Иҗади эш: укылган текст эчтәлеге буенча рәсем ясау, тел-сурәтләү |
| | | Кыш һәм кеше (Б. Рәхмәт.«Кыш һәм кеше», М. Хәсәнов. «Көн җылынды» ) | 1 | 19.12 | | |
| | | Чыршы янында (С. Урайский. «Чыршы янында», А. Хәсән. «Кыш бабай бүләк өләшә») | 1 | 26.12 | | |
| | | Кышкы урман (Ә. Еники. | 1 | 09.01 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Кышкы урман», Ә. Кари. «Кошлар туйдырам») | | | | чараларын кулланып, тасвирлама текст төзү.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле яттан сөйләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү |
| | | Кышкы бизәкләр (кабатлау)<br>(К. Ушинскийның «Дүрт теләк») | 1 | 16.01 | | |
| 5 | Туган илем, туган телем...<br>(5 сәгать) | Туган тел (Г. Тукай. «Туган тел») | 1 | 23.01 | | Әдәби текст белән эш: укылган текстның темасын һәм төп фикерен билгеләү, сурәтләү чараларын табу, аларның әһәмиятен һәм ролен билгеләү.<br>Бирелгән мәкальләр арасыннан әсәрнең төп фикеренә туры килә торганын сайлап алу.<br>Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Безнең ил – бәхет иле (Ә. Рәшитов. «Кояшлы ил – бәхет иле», Э. Мөэминова. «Туган телем») | 1 | 30.01 | | |
| | | Республикам минем – Татарстан (Г. Бәширов. «Безнең Татарстан») | 1 | 06.02 | | |
| | | Үз илемнең баласы мин (Р. Фәйзуллин «Синеке – илнеке», Л. Лерон. «Татар баласы») | 1 | 13.02 | | |
| | | Туган ил була бер генә (кабатлау) | 1 | 20.02 | | |
| 6 | Яз керде өебезгә<br>(5 сәгать) | Язның тәүге ае – март<br>(Ә. Бикчәнтәева. «Март аенда») | 1 | 27.02 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку, сәнгатьле уку.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең темасын билгеләү, төрле язучыларның бер темага язылган әсәрләрен чагыштыру. Әдәби тел-сурәтләү чараларының тексттан табу һәм мәгънәсен аңлау, аларның әһәмиятен билгеләү.<br>Текст нигезендә кыска монологик сөйләм әзерләү.<br>Тормыш тәҗрибәсе, шәхси |
| | | Язгы авазлар (Г. Бәширов. «Язгы авазлар») | 1 | 05.03 | | |
| | | Кар астыннан чыкты яз (Н. Мадьяров. «Ка р астыннан чыкты яз», Ф. Кәрим. «Яз җитә») | 1 | 12.03 | | |
| | | Яз керде өебезгә (Р. Миңнуллин. «Яз керде | 1 | 19.03 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өебезгә») | | | | күзәтүләргә нигезләнеп сөйләү. Иҗади эш: тел-сурәтләү чараларын файдаланып, тасвирлама текст төзү. Проект эше эшләү |
| | | Яз шатлыгы (кабатлау) (Э. Мөэминова. «Май») | 1 | 02.04 | | |
| 7 | Көлке көлә килә (3 сәгать) | Малайлар сөйләшә (Р. Миңнуллин. «Малайлар сөйләшә») | 1 | 09.04 | | Текстны кычкырып уку, сәнгатьле уку. Уку диалогы: әсәрнең исеме, рәсемнәр һәм ачкыч сүзләргә нигезләнеп, әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. Әдәби текст белән эш: укылган текстның исеме белән аның эчтәлеге арасындагы тәңгәллекне табу, автор позициясен билгеләү. Укылган текстта хикәяләүче затны үзгәртеп сөйләү, текст эчтәлеген тулы итеп сөйләү. Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку |
| | | Кызык та, кызганыч та (Ш. Галиев. «Онытылган...», З. Гомәрова. «Кайда булсын – кесәмдә») | 1 | 16.04 | | |
| | | Елмаеп та, көлеп тә (кабатлау) (Р. Вәлиева. «Бу класска ни булган?») | 1 | 23.04 | | |
| 8 | Исәнме, җәй! (3сәгать) | Исәнме, җәй! (Р. Вәлиева. «Исәнме, җәй!», Ш. Камал. «Җәйге иртә») | 1 | 30.04 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып уку. Уку диалогы: укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирү. Әдәби текст белән эш: әсәрнең лирик героена характеристика, тексттан тел-сурәтләү чараларын табу. Рәсемнәр һәм иллюстрацияләргә карап сөйләү Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Иҗади эш: тормыш тәҗрибәсе, шәхси күзәтүләргә нигезләнеп, кыска сочинение язу. Тикшерү эше: тест |
| | | Җәй көтә безне (Л. Лерон. «Җәй көтә безне», Р. Хисмәтуллин « Июль аланы») | 1 | 07.05 | | |
| | | Яхшы бел үткәннәрне (гомумиләштереп кабатлау) | 1 | 14.05 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |

**3 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Үткәрү вакыты | | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт | |
| 1 | Китап – белем чишмәсе (6 сәгать) | Иң якын дустым (Ж. Тәрҗеманов. «Якын дус») | 1 | 06.09 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып һәм эчтән уку.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә укылган әсәрнең темасын һәм төп фикерен билгеләү, текстка карата сораулар, шулай ук проблемалы сораулар төзү, әсәр геройларын, аларның эш-гамәлләрен бәяләү, геройларның хисләрен белдерүче тел-сурәтләү чараларын табу, билгеләү, тексттан әдәби тел-сурәтләү чараларын табу һәм мәгънәсен аңлау, аларның әһәмиятен билгеләү<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү. |
| | | Китап укый балалар(М. Гафури. «Китап һәм балалар») | 1 | 13.09 | | |
| | | Кадерле китап(В. Нуриев. «Китап»,Г. Бәширов. «Китап җене кагылган малай») | 1 | 20.09 | | |
| | | Безнең китапханә(З. Туфайлова. «Безнең китапханәдә») | 1 | 27.09 | | |
| | | Китаплар да авырый(Х. Халиков. «Китап докторы») | 1 | 04.10 | | |
| | | Кешене китап үстерә (кабатлау) | 1 | 11.10 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| 2 | Халык авыз иҗаты. Әкиятләр (5 сәгать) | Борын-борын заманда... (Татар халык әкияте «Гөлчәчәк») | 1 | 18.10 | | Тыңлау: сөйләмне тыңлап кабул итү, сүзнең яңгырашын һәм мәгънәсен бердәй кабул итү.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар китереп дәлилләү.<br>Фольклор әсәрләренең текстлары белән эшләү: текст эчтәлегендәге төп, әһәмиятле якны табу, образлар системасын билгеләү.<br>Текст персонажларының портретын табу, геройларның холкы һәм аларның эш-гамәлләре арасындагы бәйләнешләрне билгеләү.<br>Тестның эчтәлеген тәфсилләп сөйләү.<br>Фольклор жанрларының аерымлыкларын табу.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Проект эше эшләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Бүген барып, кичә кайттым, мин дә булдым аларда (Татар халык әкияте «Гөлчәчәк») | 1 | 25.10 | | |
| | | Кети-кети уйныйк әле(Татар халык әкияте «Шүрәле», нугай халык әкияте «Карт һәм су анасы») | 1 | 08.11 | | |
| | | Әти-әни сүзен тыңламасаң...(Рус халык әкияте «Казлар-аккошлар») | 1 | 15.11 | | |
| | | Әкият ялган, тик шул хак: кемгә – уен, кемгә – сабак... (кабатлау) | 1 | 22.11 | | |
| 3 | Әкиятләр илендә (5 сәгать) | Алтын тарак таптым(Г. Тукай. «Су анасы») | 1 | 29.11 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып һәм эчтән уку. |
| | | Иясе юк әйбергә тимә, диләр(Г. Тукай. «Су | 1 | 06.12 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | анасы») | | | | Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар китереп дәлилләү, текст буенча сораулар әзерләү. Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп фикерен һәм темасын, вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләү, аның буенча план төзү, әкият геройларын чагыштыру. Текстның аерым (сайлап алынган) өлешләрен сөйләү. Иҗади эш: әкият сюжетын дәвам итү, аны тәмамлап кую, охшаш сюжетлы әкият иҗат итү |
| | | Иләктә су тормый, ахмакта сүз тормый(А. Алиш. «Сертотмас үрдәк») | 1 | 13.12 | | |
| | | Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр(А. Алиш. «Сертотмас үрдәк») | 1 | 20.12 | | |
| | | Әкиятләр илендәниләр бар? (кабатлау) | 1 | 27.12 | | |
| 4 | Безнең нәни дусларыбыз (7сәгать) | Кем нәрсә ярата?(«Кем нәрсә ярата» әкияте) | 1 | 10.01 | | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку. Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку. Уку диалогы: әсәрнең исеме, рәсемнәр һәм ачкыч сүзләргә нигезләнеп, әсәрнең эчтәлеген фаразлау, укылган текстның эчтәлеге буенча, телдән һәм язма рәвештә, сорауларга җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар китереп дәлилләү. |
| | | Югалган этне эзләп(Й. Миңнуллина. «Этем югалды бүген») | 1 | 17.01 | | |
| | | Әйдәле, Акбай! Өйрән син!(Р. Миннуллин. «Акбайга») | 1 | 24.01 | | |
| | | Бәхетле песи(Н. Каштанов. «Йөнтәс песи») | 1 | 31.01 | | |
| | | Тәрбиягә песи алдым(А. Бикчәнтәева. «Сөйкемсез песи», М. Җәлил. «Карак песи») | 1 | 07.02 | | |
| | | Безнең кошчыклар(Л. Әмирханова. «Минем нәни дусларым»Ф. Садриев. | 1 | 14.02 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Сары чәчкәләр») | | | | Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларын, аларның эш-гамәлләрен бәяләү. Телдән монологик һәм кара-каршы әңгәмә (диалогик) сөйләм төзү. Сөйләү: фикерләү элементлары булган хикәяләүгә корылган хикәя төзү. Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Проект эше эшләү |
| | | Миһербанлы булыйк! (Кабатлау) | 1 | 21.02 | | |
| 5 | Изге сүз (5 сәгать) | Дуслык – зур байлык(М. Галләмова. «Дуслар») | 1 | 28.02 | | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып һәм эчтән уку. Уку диалогы: укылган текст эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, текстка карата сораулар, шулай ук проблемалы сораулар да, төзү. Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларын, аларның эш- |
| | | Изге сүз(Д. Гайнетдинова. «Изге сүз») | 1 | 06.03 | | |
| | | Яхшы сүз – җанга рәхәт, яман сүз – җанга җәрәхәт(И. Туктар. «Рәхмәт һәркемгә рәхәт», Х. Халиков. «Якты сүз») | 1 | 13.03 | | |
| | | Ничек яхшы булырга(Р. Фәйзуллин . «Ничек яхшы булырга?», Р. Гыйззәтуллин. «Кеше әйбере») | 1 | 20.03 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Яхшылык эшләргә ашык! (кабатлау) | 1 | 03.04 | | гамәлләрен бәяләү. Автор позициясен билгеләү, тел-сурәтләү чараларын тексттан табу, аларның геройның хис-кичерешләрен белдерүдәге ролен һәм мәгънәсен аңлау, әһәмиятен билгеләү. План буенча текстның эчтәлеген сөйләү. Әсәрнең укылган аерым өлешләре, кисәкләре нигезендә сүз белән сурәт ясау. Иҗади эш: әсәрне (аерым бер өлешен) сәхнәләштерү (инсценировка эшләү), фикерләү элементлары белән текст булдыру. Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү. Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| 6 | Сәламәт яшибез, спорт белән шөгыльләнәбез (6 сәгать) | Хәрәкәттә – бәрәкәт(Х. Халиков. «Хәрәкәттә – бәрәкәт») | 1 | 10.04 | | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку. Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларына бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү. Әдәби тел нормаларын саклап, телдән монологик һәм |
| | | Шәп дәрес – физкультура (Җ. Дәрзаман. «Бар да җитез»,Р. Миңнуллин. «Күңелле тәнәфес») | 1 | 17.04 | | |
| | | Витаминлы хәрефләр,хәрефле витаминнар (Ш. Галиев. «Витаминлы хәрефләр»,В. Монасыйпов. «Шифалы | 1 | 24.04 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | табиблар» | | | | кара-каршы әңгәмә (диалогик) сөйләм төзү.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу, билгеле бер темага караган әсәрне сайлап алу һәм аны сыйныфта укылган әсәрләр белән чагыштыру. Китап турында хикәя төзү |
| | | Үрнәк алабыз (С. Әхмәтҗанова. «Үрнәк алыйк») | 1 | 08.05 | | |
| | | Спорт иле – Татарстан (Й. Шәрәпова. «Татарстан – спорт иле», Г. Гыйльманов. «Универсиада») | 1 | 15.05 | | |
| | | Сәламәт яшибез, спорт белән шөгыльләнәбез (кабатлау) | 1 | 22.05 | | |

**4 класс – 34 сәгать (татар телендә белем бирү мәктәпләренә)**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Үткәрү вакыты | | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт | |
| 1 | Матурлык минем белән (6 сәгать) | Көмеш кыңгырау мәктәпкә чакыра(Р. Вәлиев. «Яшә, көмеш кыңгырау», Ф. Садриев. «Могҗизалы дөнья») | 1 | 02.09 | | Эчтән уку.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә укылган әсәрнең темасын һәм төп фикерен билгеләү, әсәргә карата куелган сорауларны аңлау, әдәби герой турында үз фикереңне дәлилләү, бу фикерне әсәрдән өзекләр белән раслау, текстны мәгънәви өлешләргә бүлү, план төзү һәм аны текст эчтәлеген сөйләгәндә куллану.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен |
| | | Зәңгәр күк, алтын кояш(В. Хәйруллина. «Хозурлык һәм горурлык») | 1 | 09.09 | | |
| | | Кошлар да китеп барды(Р. Миңнуллин. «Атказанган сандугач») | 1 | 16.09 | | |
| | | Җирдә безгә ни кирәк?(Ш. Галиев. | 1 | 23.09 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Җирдә миңа ни кирәк?») | | | | тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Хыял диңгезендә(Г. Мөхаммәтшин. «Хыял») | 1 | 30.09 | | |
| | | Матурлык минем белән (кабатлау) | 1 | 07.10 | | |
| 2 | Татар халык иҗаты. Мәзәкләр (2 сәгать) | Мәзәк сөйлим, тыңлагыз | 1 | 14.10 | | Уку диалогы: халык иҗаты текстлары эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, халык иҗаты әсәрләренең аермасын күрә белү.<br>Фольклор тексты белән эш: текстның төп фикерен билгеләү, әсәр геройлары турында фикер әйтү, бәя бирү.<br>Төрле чыганаклар белән мөстәкыйль эшләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Иҗади эш: үрнәк нигезендә мәзәкләр иҗат итү.<br>Бирелгән темага проект эше эшләү |
| | | Мәзәкләр ничек туа? | 1 | 21.10 | | |
| 3 | Дуслык (7сәгать) | Минем дусларым(Б. Рәхмәт. «Минем дусларым») | 1 | 28.10 | | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Уку диалогы: әсәр эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, текстка карата сораулар, шулай ук проблемалы сораулар да, төзү.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларын характерлап бирү, аларның эш-гамәлләрен бәяләү, вакыйгалар эзлеклелеген күрсәтү.<br>Мөстәкыйль рәвештә үз сүзләре белән план төзү.<br>План нигезендә текстның (текстның бер өлешенең) эчтәлеген сөйләү.<br>Иҗади эш: фикерләүгә корылган текст булдыру, сочинение язу |
| | | Кадерле бүләк(Д. Аппакова. «Шыгырдавыклы башмаклар») | 1 | 11.11 | | |
| | | Шатлык та, кайгы да уртак(Д. Аппакова. «Шыгырдавыклы башмаклар») | 1 | 18.11 | | |
| | | Дусларың гына булсын(Р. Миңгалим. «Дусларың гына булсын») | 1 | 25.11 | | |
| | | Яңа дус таптым(Х. Халиков. «Яңа дус таптым») | 1 | 02.12 | | |
| | | Дуслар-ахирәтләр(Н. Сладков. «Дуслар-ахирәтләр») | 1 | 09.12 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Дуслык белән көчле без (кабатлау) | 1 | 16.12 | | |
| 4 | Табигать китабы (8сәгать) | Без утырткан урман үсә(З. Туфайлова. «Без утырткан урман»,Р. Хафизова. «Күңел күзе») | 1 | 23.12 | | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку.<br>Уку диалогы: текстның исеме, рәсемнәр һәм ачкыч сүзләр ярдәмендә текстның эчтәлеген фаразлау.<br>Әдәби текст белән эш: әсәр геройларына, аларның эш-гамәлләренә бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү.<br>План нигезендә текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Иҗади эш: хикәяләү характерындагы текстка тасвирлама һәм фикер йөртү юнәлешендәге элементлар өстәү, хикәя сюжетының алда мөмкин булган үстерелешен (вакыйгалар хәрәкәтен) фаразлау.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Тукран малае Шуктуган(Җ. Тәрҗеманов. «Тукран малае Шуктуган») | 1 | 13.01 | | |
| | | Шуктуган сабак алды(Җ. Тәрҗеманов. «Тукран малае Шуктуган») | 1 | 20.01 | | |
| | | Ялгышу түгел, ялгышыңны танымау начар(Җ. Тәрҗеманов. «Тукран малае Шуктуган») | 1 | 27.01 | | |
| | | Агачлар да авырый(З. Әхмәров. «Агачлар да авырый») | 1 | 03.02 | | |
| | | Яхшылык кире кайта(Ә. Баян. «Яхшылык кире кайта») | 1 | 10.02 | | |
| | | Шәфкатьле бала(Ш. Галиев. «Курыкма, тимим», Ф. Яруллин. «Серле көндәлек») | 1 | 17.02 | | |
| | | Табигать китабы (кабатлау) | 1 | 24.02 | | |
| 5 | Күңелле бәйрәмнәр (6 сәгать) | Бәйрәм бүген(Н. Гайсин. «Бүген бәйрәм», Җ. Дәрзаман.«Солдат булдым») | 1 | 02.03 | | Текстны сәнгатьле итеп кычкырып уку.<br>Уку диалогы: әсәр эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларына, аларның эш-гамәлләренә бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү, әдәби |
| | | Әниләр бәйрәме(С. Сөләйманова. «Әниләр бәйрәме») | 1 | 09.03 | | |
| | | Көяш көлә – Нәүрүз килә(Р. Хафизова. | 1 | 16.03 | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Нәүрүз килә») | | | | әсәрдән сәнгатьлелек чараларын табу.<br>План нигезендә текстны сөйләп бирү.<br>Телдән диалог һәм монолог рәвешендә фикерләр әйтү.<br>Сәнгатьле уку: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Проект эше эшләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Сабан туе, хезмәт туе, шатлык һәм бәхет туе(Р. Зәйдулла. «Сабантуй аланында», Э. Шәрифуллина. «Сабантуй») | 1 | 06.04 | | |
| | | Әйлән-бәйлән уйныйбыз(Р. Миңнуллин. «Әйлән-бәйлән») | 1 | 13.04 | | |
| | | Күңелле бәйрәмнәр (кабатлау) | 1 | 20.04 | | |
| 6 | Җиңү бәйрәме (5 сәгать) | Май килә(Р. Миңн уллин. «Май килә») | 1 | 27.04 | | Текстны сәнгатьле итеп кычкырып уку.<br>Уку диалогы: әсәр эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларына, аларның эш-гамәлләренә бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү, сәнгатьлелек чараларының әдәби әсәрдәге вазифасын һәм әһәмиятен аңлату.<br>Укылган әсәрнең бер кисәгенә, эпизодына сүз белән сурәт тудыру.<br>Балалар өчен булган вакытлы матбугат – бер-ике журнал рубрикалары белән танышу.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу |
| | | Афәт килгән илгә(Р. Корбан. «Җиңү бәйрәме») | 1 | 04.05 | | |
| | | Алтын хәрефләр белән язылган исемнәр(М. Малик ова. «Һәйкәл янында», В. Хәйруллина. «Билгесез солдат») | 1 | 11.04 | | |
| | | Сугыш турында сөйләшә картлар(Р. Харис. «Сугыш турында сөйләшә картлар», Ф. Садриев. «Бабай сугышта булган») | 1 | 18.04 | | |
| | | Җиңү бәйрәме (кабатлау) | 1 | 25.04 | | |